ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**25.09.2017ел.**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2446**

Зеленодольск муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле муниципаль унитар предприятиеләрнең чиста табышын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 42, 62 статьялары, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 295 статьясы, 2002 елның 14 ноябрендәге «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 161-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле муниципаль унитар предприятиеләрнең чиста табышын билгеләү тәртибен әлеге карарда бирелгән кушымтаны расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең хисап чорыннан соң килүче елның 01 августына кадәр Зеленодольск муниципаль районы бюджетына чиста табыш өлешен күчерүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең хисап бирүнең тулылыгы һәм вакытында бирелүе, чиста табышның бер өлешен бюджетларга мәҗбүри түләүләр кертү өчен персональ җаваплылыгын билгеләргә.
4. Әлеге карарның 2 пунктының үтәлешен контрольдә тотуны «ЗМР мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җитәкчесенә, әлеге карарның 3 пунктын үз җаваплыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

Кушымта

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2017 елның 25
сентябрендәге 2446 номерлы карарына

## Зеленодольск муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле муниципаль унитар предприятиеләрнең чиста табыш өлешләрен билгеләү тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Зеленодольск муниципаль районы бюджетына салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләрдән соң калган Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең муниципаль унитар предприятиеләре табышының күләмен билгеләү һәм аларны күчерү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексының 42, 62 статьялары, Россия Федерациясе Граждан кодексының 295 статьясы, 2002 елның 14 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында»161-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы нигезендә муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында эшләнде.

1.2. Әлеге Тәртип муниципаль унитар предприятиеләрнең салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләрдән соң Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелергә тиешле табыш өлешен түләү күләмен һәм срокларын билгели (алга таба - Табышның бер өлеше).

1.3. Мөлкәте хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендә булган муниципаль унитар предприятиеләр табышның бер өлешен түләүчеләр дип таныла.

1.4. Муниципаль унитар предприятиеләр Табышының бер өлеше керемнәреннән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең администраторы (алга таба – Бюджет) булып «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе (алга таба - Администратор) тора.

### II. Муниципаль унитар предприятиеләр табышының бер өлеше күләмен билгеләү тәртибе

2.1. Муниципаль унитар предприятиеләр өчен Табышның түбәндәге күләмен билгеләргә:

1) 0 процент - юкка чыгу стадиясендә, шул исәптән финанс яктан савыктыру яисә банкротлык стадиясендә.булган муниципаль унитар предприятиеләр өчен.
2) 30 процент - башка предприятиеләр өчен.

2.2. Зеленодольск муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле табышның бер өлеше, салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләрдән соң предприятие карамагында калган муниципаль унитар предприятие табышының бер өлеше буларак билгеләнә.

## III. Хисаплылык

3.1. Исәп-хисап чоры булып календарь ел тора.

3.2. Чиста табыш (бүленмәгән табыш) бухгалтерлык хисабы мәгълүматлары нигезендә билгеләнә.

3.3. Бюджетка Табышның бер өлешен күчерү предприятие тарафыннан хисап чорыннан соң киләсе елның 01 августына кадәр башкарыла.

3.4. Муниципаль унитар предприятиеләр, салым салуның сайлап алынган системасына карап, хисап чорыннан соң килүче елның 6 апреленнән дә соңга калмыйча, Администраторга еллык бухгалтерлык хисабы бирәләр.

3.5. Хисап чорына күчерелергә тиешле Табышның алдагы чорда исәпләнгән һәм кертелгән өлешенә карата түләүне киметүгә китергән бухгалтерлык исәп-хисабы һәм хисап мәгълүматлары төзәтелгән очракта, барлыкка килгән артык түләү булачак түләүләр хисабына исәпкә алынырга яки предприятиегә кайтарылырга тиеш.